ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 11 2022 г. № 814

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым Административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 февралендәге 52 номерлы карары белән расланган 16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахка керү өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган тышкы мәгълүмат чарасын (дизайн-проект) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 ноябрендәге 985 номерлы карары белән расланган авыр йөкле һәм (яки) зур габаритлы транспорт чарасы автомобиль юллары буйлап йөрүгә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5 пунктындагы 8 абзацында «(алга таба – гариза)» сүзен «(алга таба – гариза, сорату)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүченең соратуның һәрбер электрон формасы кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати белдерү аша хәбәр ителә.».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 июнендәге 346 номерлы карары белән расланган Түбән

Кама муниципаль районы авыл җирлекләрендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 79 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 36 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга бирем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 августындагы 478 номерлы карары белән расланган урынны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле яки үзгәртеп корылырга тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 35 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга проект документларын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 августындагы 478 номерлы карары белән расланган урынны торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5.2 пунктында «(алга таба – гариза)» сүзен «(алга таба – гариза, сорату)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүченең соратуның һәрбер электрон формасы кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырын ачыклангандa, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати белдерү аша хәбәр ителә.».

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 9 сентябрендәге 599 номерлы карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 99 номерлы карары белән расланган өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф

оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5 пунктындагы 11 абзацында «(алга таба – гариза)» сүзен «(алга таба – гариза, сорату)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүченең соратуның һәрбер электрон формасы кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырын ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати белдерү аша хәбәр ителә.».

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 июлендәге 427 номерлы карары белән расланган авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләренә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз судноларның очышларына (максималь очып китү массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава судноларының очышыннан тыш), Түбән Кама муниципаль районы җирлеге территориясе өстеннән бәйләнгән аэростатларны күтәрүгә, шулай ук мәгълүматлар аэронавигация документларында бастырылмаган торак пунктлар чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга утыртуга (очып китүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.2. Административ регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза, сорату) астында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 3 пункты (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла.»;

Регламентның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүченең соратуның һәрбер электрон формасы кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырын ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати белдерү аша хәбәр ителә.».

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Г.Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874